**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423750, Уразай авылы,
Центральная ур., 4 йорт
тел. факс.: (85552) 3-44-42
e-mail: Uraz.Akt@tatar.ru

**СОВЕТ УРАЗАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423750, дер.Уразаево, ул.
Центральная, дом 4
тел. факс.: (85552) 3-44-42
e-mail: Uraz.Akt@tatar.ru

---

**КАРАР**
**26 ноябрь 2020 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№14**

Татарстан Республикасы Актаныш районы Уразай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 7 августындагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Уразай авыл җирлеге Советы карар бирә.

Карар:

1. Уразай авыл җирлеге территориясендә 2021 нче елда, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем,балачактан инвалидлардан кала, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.:

**Юл эшчәнлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата:**

-юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм ЩПС салу, грейдлау, кардан чистарту)

**Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:**

-ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;

- зират коймасын ремонтлау;

**Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү:**

- рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру;

**Җирлек чикләрендә Халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

-торак пунктларда су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын ремонтлау һәм лицензияләү;;

- урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;

**Җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү эшен оештыру:**

- авыл җирлеге территориясендә агач кисү;

- Сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;

- җирлек торак пунктларында хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм киртәләү.;

**Җирлек милкендә булган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау, куллану һәм популярлаштыру, җирлек территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау:**

- һәйкәлне ремонтлау һәм реконструкцияләү;

2. Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге гражданнарының авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында җыелу нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәсен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлеге"бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Уразай авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Ахметов